| | |
|---|---|
| **РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН МЕНДЕЛЕЕВСКИЙ ГОРОДСКОЙ СОВЕТ МЕНДЕЛЕЕВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА** | **ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МЕНДЕЛЕЕВСК МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ МЕНДЕЛЕЕВСК ШӘҺӘР СОВЕТЫ** |
| **РЕШЕНИЕ** | **КАРАР** |
| 06.04.2026 ел | № 16 |

Менделеевск муниципаль районы Менделеевск шәһәр Советының 2024 елның 23 октябрендәге 81 нче номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясе Салым кодексының беренче һәм икенче өлешләренә, Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү һәм Россия Федерациясе закон актларының (закон актларының аерым нигезләмәләренең) үз көчләрен югалтуын тану турында» 2025 елның 28 ноябрендәге 425 номерлы Федераль закон, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы законы белән, Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы “Менделеевск шәһәре" муниципаль берәмлеге Уставына таянып,

Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Менделеевск шәһәр Советы

КАРАР ЧЫГАРДЫ:

1. Менделеевск муниципаль районы Менделеевск шәһәр Советының «Физик затлар мөлкәтенә салым турында» 2024 елның 23 октябрендәге 81 нче номерлы карарына (алга таба - Карар) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 2 пунктның 2.5 пунктчасын үзгәртергә һәм яңа редакциядә бәян итәргә:

“Һәркайсының кадастр бәясе 300 миллион сумнан артып киткән салым салу объектларына карата 2,5 процент, проектлана торган билгеләнеше күпфатирлы йорт булган төзелеп бетмәгән объектлардан тыш".

2. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән, әмма әлеге карар рәсми басылып чыккан көннән кимендә бер ай узгач үз көченә керә һәм 2026 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында бастырып чыгарырга http://pravo.tatarstan.ru һәм Менделеевск муниципаль районының рәсми сайтында

http://mendeleevsk.tatarstan.ru “Норматив документлар" бүлегендә урнаштырырга

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районының Финанс-бюджет палатасына йөкләргә.

Рәис урынбасары Н.Н. Сөләйманов